РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 24 » 12 2020 г. №963

«2021-2025 елларга Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районында дәүләт милли
сәясәтен гамәлгә ашыру” муниципаль программасын
раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясе турында» 2012 елның 19 декабрендәге 1666 номерлы Указы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт милли сәясәте концепциясен раслау турында» 2008 елның 3 июлендәге ПУ-312 номерлы Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте Концепциясе турында» 2013 елның 26 июлендәге ПУ-695 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2020 елның 28 апрелендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советының 2006 елның 12 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында 2021-2025 елларга дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасын расларга .
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында

Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче С. П. Самонина

М. М. Килячкова
2-88-02

**"2021-2025 елларга**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА ДӘҮЛӘТ МИЛЛИ СӘЯСӘТЕН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ"**
**МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ**

ПРОГРАММАНЫҢ ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасы (алга таба - Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез | «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясе турында» Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 19 декабрендәге 1666 номерлы Указы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы дәүләт милли сәясәте концепциясен раслау турында» 2008 елның 03 июлендәге ПУ-312 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы, «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте концепциясе турында» Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 26 июлендәге ПУ-695 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советының 2020 елның 28 апрелендә №18 карары белән кабул ителгән «Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советының 2006 елның гыйнварында №1 карары белән кабул ителгән Башкарма комитет турында Нигезләмәсе |
| Программаның заказчысы | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) |
| Программаны төп эшләүче | «Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге» МКУ (алга таба - «Мәдәният бүлеге» МКУ) |
| Программаның максаты һәм бурычлары | Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру, Татарстан Республикасы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы (алга таба - Район) территориясендә яшәүче халыклар вәкилләренең цивилизацияле үсеше, милләтара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны саклап калу, гомумроссия граждан тәңгәллеген (Россия милләтен) ныгыту, мигрантларны уңышлы социомәдәни адаптацияләү һәм интеграцияләү.<br>Программаның бурычлары:<br>1. Гомумроссия гражданнар тәңгәллеген ныгытуга ярдәм, милләтара һәм конфессияара тынычлыкка һәм татулыкка ярдәм итү, мигрантларның социомәдәни җайлашуы һәм интеграциясе өчен шартлар тудыру; |

<table>
<tr><td></td><td>2. Районда яшәүче халыкларның этномәдәни үсеше өчен шартлар тудыру;<br>3. Районда дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруны фәнни-белем бирү һәм мәгълүмати тәэмин итү.</td></tr>
<tr><td>Программаны гамәлгә ашыру<br>сроклары</td><td>2021 - 2025 еллар</td></tr>
<tr><td>программаны финанслауның<br><br>күләме һәм чыганаклары</td><td>
<table>
<tr><td rowspan="2">Ел</td><td colspan="2">Фаразланган чаралар күләме, мең сум.</td></tr>
<tr><td>ҖБ</td><td>ВБ</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>11</td><td>800</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>11</td><td>820</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>11</td><td>840</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>11</td><td>860</td></tr>
<tr><td>2025</td><td>11</td><td>880</td></tr>
</table>
<br>Программаны финанслауның гомуми күләме 4 255 мең сум тәшкил итә, шуларның 55 мең сумы - җирле бюджет акчалары;<br>4 200 мең сум - эшкуарлык һәм керемне китерә торган башка эшчәнлектән акчалар, иганәчелек ярдәме һәм хәйрия иганәсе акчалары.<br>Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз характерында һәм Район бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.<br>*ҖБ - җирле бюджет<br>ВБ - эшкуарлык һәм башка эшчәнлекнең керемен китерә торган чаралар, иганәчелек ярдәме һәм хәйрия иганәсе акчалары.</td></tr>
<tr><td>Программаны гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре</td><td>Программаны тормышка ашыруның ахыргы нәтиҗәләре:<br>• Районда дәүләт милли сәясәте концепциясен гамәлгә ашыру, экстремизмга каршы тору, ксенофобия күренешләренә, милли һәм раса каршылыгына, район территориясендә этник дискриминациягә каршы тору буенча җирле үзидарә органнары эше рәвешләрен һәм ысулларын камилләштерү;<br>• интернационализм мәдәниятен, этникара татулыкны, җәмгыятьтә, яшьләр даирәсендә, мәгариф учреждениеләрендә укучылар һәм тәрбияләнүчеләр арасында интернационализм мәдәниятен тарату һәм үстерү;<br>• террорчылык һәм экстремистик күренешләр, ксенофобия фактларына карата килешеп карамау сыйфатын тәрбияләү;<br>• башка этник һәм конфессиональ бергәлекләр вәкилләренә толерант, гуманлы һәм хөрмәт белән карау мөнәсәбәтен формалаштыру;<br>• Район территориясендә толерантлык, гражданлык теләктәшлеге, башка культураларга, шул исәптән муниципаль массакүләм мәгълүмат чаралары аша да, пропагандалау һәм</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | тарату өчен бердәм мәгълүмат киңлеге формалаштыру. |
| Программаның үтәлешен тикшереп тору | Программаның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет башкара. |

## I. АКТУАЛЬЛЕК

Районда милләтара мөнәсәбәтләрнең торышы тотрыклылык, төрле этник төркемнәр һәм конфессияләр вәкилләренең үзара тыныч аралашуы һәм хезмәттәшлеге белән характерлана.

Районның үзенчәлеге - халыкның полиэтниклыгы һәм төрле дин тотуы, аларның үсеше район территориясендә яшәүче халыкларның гореф-гадәтләренең тыгыз этномәдәни бәйләнеше һәм үзара үтеп керүе, йогынтысы белән характерлана. Бу процесста гадәттәгечә татар һәм рус халыклары вәкилләре зур роль уйный. Алар район территориясендә яшәүче башка халыклар белән чагыштырганда күпчелекне тәшкил итә. 2020 елның 1 гыйнварына халык саны 20 316 кеше тәшкил итте. Шулардан:

| № Т/Б | Милләт | тиешле милләт вәкилләре саны, кеше | халыкның гомуми санына карата %ларда |
|---|---|---|---|
| 1. | 1.3.1 татарлар | 15 004 | 74,6 |
| 2. | 1.3.2 руслар | 4 465 | 21,3 |
| 3. | 1.3.3 чувашлар | 108 | 0,5 |
| 4. | 1.3.4 башкортлар | 182 | 0,9 |
| 5. | 1.3.5 мордвалар | 45 | 0,2 |
| 6. | 1.3.6 украиналылар | 109 | 0,5 |
| 7. | 1.3.7 башка милләтләр | 403 | 2,0 |

Районда төрле мәдәният һәм дин вәкилләренең озак еллар бергә яшәү дәверендә барлыкка килгән татулык традицияләре бүгенге көндә дә саклана. Районда элеккеге союздаш республикалардан чыккан кешеләр җәмгыятьләре формалашты.

БДБ илләреннән хезмәт мигрантлары өчен Районның җәлеп итүчәнлеге белән бәйле процесслар аеруча актуаль була башлый. Мигрантларның уңышлы социомәдәни адаптациясен һәм интеграциясен тәэмин итүдә гражданлык җәмгыяте институтлары зур роль

уйный. Алар арасында «Татарстан - новый век" - "Татарстан - яңа гасыр" республика иҗтимагый хәрәкәтенең Ютазы территориаль бүлеге, Бөтендөнья татар конгрессының Ютазы муниципаль районы буенча җирле бүлекчәсе, район хатын-кызлар советы, дини оешмалар белән хезмәттәшлек советы мөһим урын алып тора. Районда Ютазы муниципаль районының Иҗтимагый Советы төзелде, аның устав бурычы булып тероризмны һәм экстремизмны профилактикалау тора.

Эшне Татарстан Республикасы кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Ютазы муниципаль районы буенча җәмәгать ярдәмчесе алып бара.

Районда 14 дини оешма эшли, шул исәптән бер православие чиркәве, «Фәнис» мәдрәсәсе һәм якшәмбе православие мәктәбе, Бәйрәкә авылындагы «Гобәйдия» мәдрәсә музее.

Шул ук вакытта мигрантларны хокукый яктан агарту җитәрлек оештырылмаган, җәмгыятьтә интеграцияләүне социаль-мәдәни җайлаштыру эше, мәдәниятара аралашу дәрәҗәсе түбән һәм кабул итүче бергәлек белән мигрантлар арасындагы ышаныч түбән.

Этносмәдәни үсеш, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр мәсьәләләрендә идарә итү системасы, мәгариф, мәдәният учреждениеләре, яшьләр сәясәте һәм массакүләм мәгълүмат чаралары кадрларының квалификациясен һәм компетентлыгын күтәрү мөһим бурыч булып тора.

Этник һәм дини үзаң һәрвакытта да гармонияле формалаша алмый. Кайбер очракларда дини эчтәлек халыкларның тарихи формалашкан этномәдәни үзенчәлеген юкка чыгара. Район өчен традицион булмаган дини агымнарның үтеп керүе күзәтелә.

"Хәвефле төркем"дә яшьләр кала, бу социаль-икътисадый һәм этнодини факторларга бәйле. Яшь кешеләрнең гомуми белем бирү һәм гомуми культура дәрәҗәсенең кимүе аеруча сагайта, моның белән экстремистик карашлы, радикаль сәяси һәм дини көчләр файдалана.

Районда милләтара тынычлыкны һәм татулыкны саклау буенча уңай тәҗрибә тупланган, башлангыч стадиядә экстремизм куркынычын бетерү, халыкның толерантлыгын арттыру һәм этносоциаль һәм дини каршылыкларны җиңү буенча актив эш алып барыла.

Районда гы социаль-икътисадый һәм иҗтимагый-сәяси вазгыятьне яхшыртуда мөһим шартларның берсе - экстремизмга, террорчылыкка, хокук бозуларга китерүче сәбәпләрне һәм шартларны кисәтүгә, ачыклауга, юкка чыгаруга юнәлтелгән чараларга системалы якын килү.

Милли сәясәт стратегиясеннән килеп чыга торган чараларны һәм бурычларны гамәлгә ашыру өчен Районда милли сәясәтне гамәлгә ашыру буенча муниципаль программа кирәк. Ул җирле халыкның, бигрәк тә яшьләрнең, башка этник, конфессиональ бергәлекләр вәкилләренә карата толерант, гуманлы һәм ихтирамлы мөнәсәбәтен формалаштыру өчен тиешле шартлар тудыруны тәэмин итәчәк.

Программа җирле үзидарәнең һәм гражданлык җәмгыятенең төрле институтларының җәмгыяттәге конфессияара, этникара тынычлык һәм татулыкны тәэмин итүгә, экстремизмга, ксенофобия күренешләренә, милли, раса каршылыгына һәм район территориясендә этник дискриминациягә каршы көрәшкә юнәлтелгән эшчәнлегендәге мөмкинлекләреннән максималь файдалануны күздә тота.

Программа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү өчен ачык документ булып тора.

## II. ПРОГРАММАНЫҢ МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

Программаның максаты - Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру, Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләренең цивилизацияле үсеше, милләтара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны саклау, гомумроссия гражданлык тәңгәллеген (Россия милләтен) ныгыту, мигрантларның уңышлы социомәдәни адаптациясе һәм интеграциясе.

Куелган максатларга ирешү түбәндәге бурычларны гамәлгә ашыруны күздә тота:

1. Гомумроссия граждан тәңгәллеген ныгытуга ярдәм, милләтара һәм конфессияара тынычлыкка һәм татулыкка ярдәм итү, мигрантларның социомәдәни җайлашуы һәм интеграциясе өчен шартлар тудыру;

2. Районда яшәүче халыкларның этномәдәни үсеше өчен шартлар тудыру;

3. Районда дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруны фәнни-белем бирү һәм мәгълүмати тәэмин итү.

Программада түбәндәгеләр каралган:

- комплекслы мәгълүмат кампаниясе уздыру һәм патриотизмны һәм гомумроссия граждан тәңгәллеген булдыруга һәм ныгытуга юнәлдерелгән мәгълүмати ресурслар булдыру;
- иҗтимагый инициативаларга һәм патриотизмны һәм гомумроссия граждан тәңгәллеген булдыруга һәм ныгытуга юнәлдерелгән чараларга ярдәм итү;
- конфликтлы хәлләр турында мәгълүмат кабул итү һәм аның эшчәнлеген тәэмин итү буенча call-үзәк башкарма хакимият органы структурасында төзү;
- милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр өлкәсендә торышны һәм тенденцияләрне билгеләү максатында социологик тикшеренүләр уздыру;
- этнополитик һәм дини-сәяси экстремизмны, ксенофобияне һәм килешеп кармауны профилактикалау;
- мигрантларның җайлашуына һәм интеграцияләнүенә ярдәм итү;

- Татарстан Республикасы, Район территориясендә яшәүче халыкларның этномәдәни үсешенә юнәлдерелгән чараларны һәм инициативаларны үтәү;
- милләтара мөнәсәбәтләр торышын мониторинглау системасын булдыру һәм озата бару һәм милләтара конфликтларны башта ук кисәтү;
- Россия халыклары турындагы белемнәрне таратуга юнәлдерелгән белем бирү чараларын гамәлгә ашыру;
- компетенцияләрендә гомумгражданлык бердәмлеге һәм милләтара мөнәсәбәтләрне гармонизацияләү мәсьәләләре булган дәүләт граждан һәм муниципаль хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү.

Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү өчен Программаның максатчан индикаторлары һәм аны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре кулланыла.

## III. ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫ

Районның җирле бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла торган программа чаралары исемлеге һәм учреждениеләрнең, предприятиеләрнең һәм оешмаларның чыгымнары сметасында каралган акчалар исәбеннән башкарыла торган чаралар исемлеге әлеге программага кушымтада китерелгән.

Программа түбәндәге юнәлешләргә таянып гамәлгә ашырыла:

- этносәяси һәм дини-сәяси экстремизмны, түземсезлекне, шул исәптән мәгълүмати тирәлектә дә профилактикалау;
- милләтара татулыкны ныгытуга юнәлтелгән социаль әһәмиятле проектларны җитештерүне, таратуны һәм тиражлауны гамәлгә ашыручы оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү.

Татарстан Республикасында, Районда яшәүче халыкларның этномәдәни үсеше өчен шартлар тудыру буенча программада куелган бурычны хәл итү түбәндәге юнәлешләрне гамәлгә ашыру юлы белән ирешелә:

- Татарстан Республикасы, Район территориясендә яшәүче халыкларның этномәдәни үсешенә юнәлдерелгән чараларны һәм инициативаларны үтәү;
- тел күптөрлелегенә ярдәм итү.

Татарстан Республикасында, Районда дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруны фәнни-мәгариф һәм мәгълүмати тәэмин итү буенча Программада куелган бурычны хәл итү түбәндәге юнәлешләрне гамәлгә ашыру юлы белән ирешелә:

- мәгълүмати кампания уздыру һәм патриотизмны һәм Россия граждан тәңгәллеген ныгытуга юнәлдерелгән мәгълүмати ресурслар булдыру;
- милләтара мөнәсәбәтләр торышын мониторинглау системасын булдыру һәм

милләтара конфликтларны башта ук кисәтү.

## IV. ПРОГРАММАНЫҢ РЕСУРС БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТЕЛЕШЕН НИГЕЗЛӘҮ

Программа чараларын финанслау Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджеты акчалары исәбенә гамәлгә ашырылачак.

Программада программадан тыш чараларны гамәлгә ашыру өчен район составына керүче муниципаль берәмлекләр бюджетларының бюджеттан тыш акчаларын (эшмәкәрләр, иганәчеләр акчаларын) һәм чараларын җәлеп итү мөмкинлеге каралган.

Программаны финанслауның гомуми күләме 4 255 мең сум тәшкил итә, шуларның 55 мең сумы - җирле бюджет акчалары; 4 200 мең сумы - эшкуарлык һәм башка керем китерә торган эшчәнлектән акчалар, иганәчелек ярдәме һәм хәйрия иганәсе акчалары.

Финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм аңа, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджетының мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

## V. ПРОГРАММАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУ МЕХАНИЗМЫ

Программа чараларын гамәлгә ашыру барышында заказчы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты төп башкаручыларның үзара хезмәттәшлеген, чараларны гамәлгә ашыруның барышын һәм чараларны нәтиҗәле куллануны тикшереп торуны тәэмин итә.

Татарстан Республикасы Башкарма комитеты ел саен Татарстан Республикасы Ютазы район Советы алдында Программа чараларын гамәлгә ашыруның барышы турында хисап тота.

## VI. ПРОГРАММАНЫҢ СОЦИАЛЬ - ИКЪТИСАДЫЙ НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕН ТАСВИРЛАУ

Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге күрсәткече - Программаның максатларына һәм бурычларына ирешү. Программаны гамәлгә ашыру, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, предприятиеләр, учреждениеләр, төрле милек рәвешләрендәге оешмалар белән беррәттән, милли сәясәт өлкәсендәге эшчәнлекне оештыруга җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк. Тулаем алганда, Районда дәүләт милли сәясәте программасын гамәлгә ашыру иҗтимагый-сәяси тормышның тотрыклылыгына ирешүгә, Район территориясендә төрле милләт һәм конфессия вәкилләре арасында тынычлыкны, үзара аңлашуны, татулыкны һәм хезмәттәшлекне тәэмин итүгә ярдәм итәчәк.